КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 1 август г.Казань № 534

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органының юридик хезмәте турындагы бертип нигезләмәне раслау хакында» 2002 ел, 12 ноябрь, 639 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органының юридик хезмәте турындагы бертип нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органының юридик хезмәте турындагы бертип нигезләмәне раслау хакында» 2002 ел, 12 ноябрь, 639 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 2 февраль, 69 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органының юридик хезмәте турындагы бертип нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның икенче абзацында «орган системасына керүче» сүзләрен «орган ведомствосындагы» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Юридик хезмәт хезмәткәре «Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 3,4 статьялары пунктлары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә югары юридик белемле булырга һәм дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән бүтән квалификация таләпләренә туры килергә тиеш.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Юридик хезмәт:

Татарстан Республикасы законнары проектларын, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары проектларын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм боерыкларын, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары эшли торган бүтән хокукый актлар проектларын әзерли яисә әзерләүдә катнаша (анализлый, хокукый экспертизаны гамәлгә ашыра);

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы норматив хокукый актлары проектларына хокукый экспертиза үткәрә;

норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрә;

мөстәкыйль рәвештә яки башка структур бүлекчәләр белән берлектә норматив хокукый актларны үзгәртү яки кире кагу (үз көчен югалткан дип тану) турында тәкъдимнәр әзерли;

мөстәкыйль рәвештә яки башка структур бүлекчәләр белән берлектә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органына керүче норматив хокукый актлар проектлары буенча нәтиҗәләр (бәяләмәләр) әзерли;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы җитәкчесенә имзага кертелә торган норматив хокукый актлар проектларына һәм бәяләмәләргә виза куя (Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасында килештерә);

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы компетенциясе өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерү буенча һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы вәкаләтләрен тәгаенләү буенча тәкъдимнәр эшләүдә катнаша;

мөстәкыйль рәвештә яки Татарстан Республикасы башкарма хакимият органының башка структур бүлекчәләр белән берлектә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы компетенциясе өлкәсендә законнар мониторингын гамәлгә ашыра;

федераль закон, Татарстан Республикасы законы яки бүтән норматив хокукый акт кабул итү белән бәйле эшләү һәм чыгару (кабул итү) кирәк булган норматив хокукый актларны билгеләнгән вакытларында әзерләү һәм чыгару буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органының структур бүлекчәләре эшен яраштыра;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 1 көненнән соңга калмыйча, Татарстан Республикасы законы белән эшләү һәм чыгару (кабул итү) каралган норматив хокукый актларны эшләү барышы һәм кабул итүнең күздә тотылган вакытлары турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына тапшыруны тәэмин итә;

Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган Россия Федерациясендә хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру методикасы нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы компетенциясе өлкәсендә куллану мониторингын гамәлгә ашыруны оештыра;

ел саен, 15 апрельгә кадәр узган елда гамәлгә ашырылган хокук куллану мониторингы нәтиҗәләре турында, хокук куллану мониторингы барышында билгеле булган норма чыгару һәм (яки) хокук куллану эшчәнлегендәге кимчелекләрне бетерү буенча күрелгән чаралар турында мәгълүматны, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында хокук куллану мониторингы турында» 2012 елның 15 маендагы ПУ-331 номерлы Указы нигезендә бүтән мәгълүматны, шулай ук киләсе елга Россия Федерациясендә хокук куллану мониторингы планы проектына тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына тапшыруны тәэмин итә;

башка структур бүлекчәләр белән берлектә законнарны куллану практикасын гомумиләштерә, аны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшли һәм аларны Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы җитәкчесе карап тикшерүенә кертә;

килешүләр, шартнамәләр проектларын әзерләүдә катнаша, шулай ук аларның хокукый экспертизасын үткәрә;

структур бүлекчәләр үткәрә торган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы норматив хокукый актларын Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен сайлап алу һәм җибәрү буенча эшендә катнаша;

судларда, башка дәүләт хакимияте органнарында һәм җирле үзидарә органнарында Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны гамәлгә ашыра, юридик затлар һәм гражданнар белән үзара багланышларда судларда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты мәнфәгатьләрен тәкъдир итә;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы системасына керә торган территориаль органнарның хокукый эше белән методик җитәкчелекне гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы, аның территориаль органнары һәм ведомствосындагы оешмалар хезмәткәрләренә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча хокукый ярдәм күрсәтә;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы җитәкчелеге өчен законнар буенча белешмә материаллар әзерли;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы компетенциясе өлкәсендә «Татарстан Республикасы гражданнарына бушлай юридик ярдәме күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру максатларында чараларны гамәлгә ашыра (гамәлгә ашыруда катнаша).»;

7 пунктның икенче абзацында «аның системасына керүче оешмалар,» сүзләрен «ведомствосындагы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта «виза куела торган» сүзләрен «виза куела торган (Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасында килештерелә торган) сүзләренә алмаштырырга, «гамәлдәге» сүзен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына 30 көн эчендә органның юридик хезмәте турында нигезләмәләргә һәм әлеге структур бүлекчәләр белгечләренең вазыйфаи регламентларына тиешле үзгәрешләрне кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин